СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №75 (7248) | 25 июнь, 1991 ел. СИШӘМБЕ | Бәясе 4 тиен.

## Район газетасына 60 яшь



Инде мәгълүм булганча, «Дуслык», «Дружба», «Туслах» район газетасы быел үзенең 60 еллык юбилеен билгеләп үтәргә җыена.

Газетада 60 ел эчендә күп талантлы журналистлар эшләгән, анда чыныгу алып зур каләм осталары үсеп чыккан. Газета архивыннан бүген бирелә торган фотода сез редакциянең 1971 елгы коллективын күрәсез.

Рәсемдә: (сулдан уңга утырганнар): ул чактагы редактор Н. И. Хәйретдинов, уртада—беренче редактор М. В. Назаров, ул чактагы җаваплы секретарь С. М. Яһүдина, рус дубляжының редактор урынбасары Г. А. Давыдова, басканнар—корреспондент В. В. Исхаков, типография директоры М. Т. Чекалин, бухгалтер И. Н. Золотухина, корректор Т. А. Сотникова, радио оештыручы А. А. Пестова, машинистка Н. И. Кубасова, тәрҗемәче Р. Г. Нуретдинова.

## ТУГАН ИЛ БУЙЛАП

### Шәһәр исеме Болгар булыр

12 июньдә Президент сайлаулары вакытында республикадагы Куйбышев районы һәм Куйбышев шәһәренең исемен ничек үзгәртү турында референдум уздырылды. Ак бюллетеньгә «Куйбышев шәһәрен Болгар дип, районын Спас районы дип үзгәртүгә сез ризамы?» дигән сорау язылган иде. Райондагы халыкның 62 проценты моңа уңай тавыш бирде. Хәзер бу эшне рәсмиләштерәсе генә калды.

## Колхоз җире—безнең җир

Узган ел «Алга» колхозының дүртенче бригадасында печән мәйданы ничек чабылган булса, шул килеш калган булган.

Быел звено печәнгә оешкан рәвештә төшә. Ә колхозның үлән басуы гаять зур—450 гектар мәйданны тәшкил итә. Менә шуны әрәм-шәрәм итмичә, югалтуларсыз җыеп алу өчен механизаторлар уртак тырышлык куялар да. Хәзерге вакытта печәнне дүртенче бригада басуында җыялар.

—Хуҗалык буенча дүртенче кибәнне куябыз,—ди де ялга туктаган СШР агрегаты тракторчысы Илдус Зиятдинович Сәгъдиев.—Печән әйбәт, шытырдап кипкән. Мондый темпта эшләгәндә печән җыю озакка сузылмас төсле.

МТЗ-80 тракторында Рамил Вәлиев һәм Т-16 тракторында Илдус Рәхимов КСК-2,1 чапкычы белән дүртенче бригададагы 50 гектар мәйданлы печәннең 38 гектарын чапканнар. Колхоз шуның 12 гектарын орлыкка калдырырга исәпли.

Артта тагын бер тракторның килүе күренде. Мөнир Хәйруллин икән. ГВК-6 агрегаты белән печәннән кибәннәр ясап баруы.

Кибән башында торучы Шәүкәт Мортазин, Камил Фәйзуллин һәм пенсионер карт Әнәс Мифтаховның да хезмәтләре җиңел түгел. Аларга печәнне тыгызлап өлгереп барырга кирәк.

Илгизәр Зарипов җитәкчелегендәге бу звено бүгенге көнгә 100 тонна печән әзерләгән инде. Аларга тоткарлыксыз эшләсеннәр өчен, барлык төр кайгыртучанлык чаралары да күрелә. Кирәк чагында кырга алмаш комбайнчы килә. Сүз уңаеннан әйтеп үтәргә кирәк, Көрнәле Әмзәдә Харис Мифтахов, Рәшит Насыйбуллин, Наил Мортазин металлоломга ташланган иске тимер-томырларны җыеп, трактор ясаганнар. Хуҗалыкта аларның да техникасын файдаланалар.

Сенаж, силос кайтару өчен азык базы да тулы тәртиптә. Аны Тольятти шәһәреннән колхозга үз теләге белән эшкә кайткан Т-4 тракторчысы Рәшит Гәлләмов чистарткан. Ул әле өченче аен гына эшли. Хәзерге вакытта донник яшел массасын тыгызлап тора. Рәшитне хезмәттәшләре карусыз, тырыш булуы өчен хөрмәт итәләр. Колхоз да егеткә бурычлы булып калмаска тырыша, кыска гына вакытта фатир алып бирергә вәгъдә иткән.

Эшкә игътибар арткан да, кешегә дә хөрмәт арта. Моны «Алга» колхозы механизаторлары үз практикаларында раслыйлар.

Г. РӘХИМОВА.

## Күмәк көч белән

**Хафизов исемендәге колхоз.** Колхозның чөгендер җире 300 гектар мәйдан били. Шуның 20 гектарын азык чөгендере тәшкил итә.

Анда Сәгыйрь Җәлалов, Әхәт Моратов, Валентин Таймуллин, Николай Ильдухин җитәкләгән звенолар рәт араларын эшкәртеп бетереп, хәзерге вакытта янә тамырдан тукландыру алып баралар. Татлы тамыр плантацияләрендә беренче кат сирәкләү эшләре дә төгәлләнде инде. Аны кыска срокларда һәм сыйфатлы итеп башкаруда колхозның хатын-кызлары зур тырышлык куйдылар. Шундыйлардан Хәлисә Минебаева, Чәчәк Ганиева, Гөлсәрия Гатина, Зәкия Кәримова, Зина Сергеева, Валентина Ялина, Валентина Игнатьеваларны атарга була. Алар 4,5 әр гектар мәйданда чөгендер сирәкләделәр. Сания Вәлиәхмәтова исә балалары белән 9 гектарга якын чөгендер җире эшкәртте.

Хуҗалыкка район китапханәсе һәм тара ремонтлау базасы эшчеләре дә ярдәмгә килделәр.

Хезмәткә түләү һәм шикәр комы бирү мәсьәләләре ярдәмгә килүчеләргә дә колхозчылар белән бер үк дәрәҗәдә каралганга, шәһәрдән дә 6—7 кеше үзләре теләп чөгендер сирәкләүдә катнаштылар.

## Вакыт белән исәпләшмиләр

**«Игенче» колхозы.** Терлек азыгы хәзерләүдә җәйнең һәр көнен отышлы файдалану өчен тырыша бүген игенче.

Соңгы вакытларда көннәрнең аяз торуы печәнчеләр өчен аеруча яхшы шартлар тудырды. 180 гектар мәйдандагы күпьеллык үлән басуы бүгенге көндә гөжләп торган умарта күчен хәтерләтә. Тракторчылар Вәзир Хөснетдинов һәм Хәлим Мөхәммәтшин КС-2,1 чапкычы белән чапкан печәнне МТЗ-80 тракторына тагылган ПК-1,6 агрегатларында Айрат Фәхриев, Равил Хисмәтов, Ранас Мифтахов әйләндереп баралар. Кайбер башка хуҗалыклардан аермалы буларак, биредә терлек азыгын турыдан-туры азык базына ташыйлар. Аны ташуда КамАЗ машинасы шоферы Ришат Гафуров, Т-150 тракторчылары Вәли Гыйләҗев, Әсхәть Ибраһимов, Т-40 тракторчысы Ринат Хәкимов өлгерлек күрсәтәләр. Алар көненә 10—12 шәр рейс ясыйлар.

В. КАНЯФИНА, экономист.

## Печән җыю тәмамланды

«Россия» колхозында күпьеллык үләннәр мәйданнары зур түгел, 140 гектар. Соңгы көннәрдәге кояшлы эссе һава авыл кешеләренә җәмәгать маллары өчен җитәрлек күләмдә азык хәзерләргә мөмкинлек бирде. Хуҗалык эшчәннәре июнь башында ук оешкан төстә печән җыярга чыкканнар иде. Эшне ике сменада алып бардылар. Көндез колхозчылар наряд буенча эшкә чыксалар, кичен барлык административ аппарат хезмәткәрләре алмашка килделәр.

Үләннәрне чабуда Владимир Имуков аерата тырышлык күрсәтте. КС-2,1 агрегатында эшләүче Александр Михеев һәм Юрий Имуков та вакыт белән санашмыйча, караңгыга кадәр эшләделәр. Печән җыюда Владимир Павловның өлешен дә күрсәтергә кирәк. Аның ПК-1,6 агрегаты соңгы көннәргә кадәр тик торуны белмәде. Бер үк тракторда эшләүче Владимир Давыдов һәм Владимир Артемьевның да күрсәткечләре әйбәт.

Печән өсте кешеләрне икеләтә энергия белән эшләргә мәҗбүр итте. Шоферлар иртә белән сөтмай заводына әчетке алырга барырга да, шуннан соң печән җыюга чыгарга да өлгерделәр, кичен исә янә заводка юнәләләр иде. Петр Перепелкин КВК-6 агрегаты белән теземнәрне чүмәләгә куйды, ә Геннадий Михеев кибән куйгыч белән әйбәт эшләде. Бер сүз белән әйткәндә, хуҗалыкта печән җыю уңышлы төгәлләнде, 200 тоннадан артык сыйфатлы печән әзерләнде. Шушы көннәрдә «Россия» колхозы эшчәннәре «Төрнәс» совхозының Единение поселогындагы кырына барырга җыеналар. Килешү нигезендә алар биредәге мәйданнарны чабарга булышалар, һәм шулай итеп печән запасын тагын да арттырачаклар.

З. ЯЛЛИНА.

## Беренчеләрдән булып кайтты

«Восход» колхозының III съезд поселогы перспективасыз авыллар исемлегендә тора иде. Ләкин соңгы вакытларда биредә дә үзгәрешләр сизелә башлады. Авылга эшкә кайтырга теләк белдерүчеләр барлыкка килде.

Совет Армиясе сафларында хезмәт итеп кайткач та, анасын ялгыз калдырып читкә киткән Петр Владимирович Тарасов яңадан туган авылына механизатор булып әйләнеп кайтты. Бүгенге көндә ул ДТ-75 тракторы белән 250 гектар мәйдандагы чиста пар җирендә эшли һәм сөрүдә көнлек норманы арттырып үти.

# Газ һәркемгә кирәк

Көнкүрешебезгә газ куллану күбрәк кергән саен, шәһәр газ службасы вазифалары катлаулана, йөк арта бара. 100 кешене берләштергән бу коллектив шәһәр генә түгел, бөтен район халкын газ белән тәэмин итүдә зур хезмәт күрсәтә. Төгәлрәк итеп әйткәндә, коллектив өч төп юнәлештә эшли: газ эксплуатацияләүдә куркынычсызлыкны тәэмин итә, Әлмәт шәһәреннән автоцистерналар белән газ ташый, аны газ тутыру пунктында баллоннарга бүлеп, халыкны газ белән тәэмин итә, шәһәрдә һәм районда табигый газүткәргечләр төзелешенә курьерлык итә.

Күргәнебезчә, һәр төр эш халыкның көнкүрешен җиңеләйтү, аны тоткарлыксыз газ белән тәэмин итүгә юнәлтелгән. Бу җәһәттән төп нагрузка газ тутыру пунктына төшә. Аларга чималны һәр көнне 4 машинада ташый. Шоферлар Виктор Иванович Маликов, Рәис Галимович Мусин, Виктор Кузьмич Савинов, Алексей Семенович Жуков елның теләсә нинди вакытында шул юлда булалар. Аена алар 17—19ар рейс ясыйлар, бу бертөрле, ялыктыргыч юл өстәвенә куркыныч та. Аларга төшкән хезмәтнең бермә-бер артуын түбәндәге күрсәткечләрдән дә күреп була: 3 ел элек елына 1500 тонна сыеклатылган газ реализацияләнсә, 1990 елда ул 2941 тоннага җитте. Газ тутыру пунктының тәүлеклек эшләп чыгару күләме дә 19—20 тонна тәшкил итә хәзер. Пункт җитәкчесе Әхмәтҗан Әхмәтҗанович Хәммәтвәлиев һәм мастер Исламия Галимҗановна Сибгатуллина кул астында бирәдә 22 кеше эшли. Эш конвейер системасы буенча көйләнгән, авыр. Операторларга эш урыныннан бер минутка да читкә китәргә юк, зур баллоннарны кысу да кулдан башкарыла. Әмма операторлар З. Е. Казюкова, Н. С. Иванова, Т. В. Кандалина, Ф. М. Вәлиева кебек күптән бу хезмәткә күнеккән бик җаваплы эшчеләр булганда, коллектив хезмәтен уңышлы оештырып була, әлбәттә. Тик шулай да юк-юк та газ баллоннары белән тәэмин итүдә халыктан моң-зар булгалап ала. Монда һәр ике якны да аңларга кирәк: бер яктан, газ ташу машиналары иске, алар еш сафтан чыгалар. Әле менә күптән түгел генә газ тутыру пунктының бер конвейеры ватылган иде. Шул ук вакытта заказчыларның үзләреннән дә төгәллек сорала: һәр йортка ике баллон булдырырга, заказ биргән вакытка өйдә булырга тырышырга кирәк. Тутырылган баллоннарны ташучы шоферлар Н. Сенькин, А. Рак, А. Сидоров еш кына бер үк фатирны берничә кат урарга мәҗбүр булалар.

Газ тутыру пунктында баллоннарны тикшерү, ремонтлау да үткәрелә. Бусын слесарьлар И. Маликов, В. Тимофеев башкаралар. Әлегә коллектив район халкын сыекландырылган газ белән тәэмин итү бурычын әйбәт кенә үтәп килә. Шул ук вакытта алар хезмәтен җиңеләйтеп, районга табигый газ килә. Авылларны һәм шәһәрне газлаштыруга техник күзәтү алып бару, аны кабул итү, файдалануга тапшыру эше шулай ук шәһәр газ службасына йөкләтелгән.

Табигый газ безнең якта иң беренче булып 1986 елда пәйда булды. Шуннан соңгы елларда районда 18 км да түбән һәм урта басымлы газүткәргеч сузылды, шәһәрдә 5 котельня, 1500 фатир газлаштырылды, 4 газ бүлү пункты төзелде. Хәзер бездә бу эшне 2 нче ПМК, «Монтаж» кооперативы, «Татспецстрой» РСУсы һәм башкалар алып бара. Нигездә эш шәһәрнең тимер юлчылар һәм шикәрчеләр поселогы ягында һәм район авылларында бара. Хафизов исемендәге колхозның Кормыш поселогында да быел табигый газдан файдаландылар инде.

Быел зәңгәр ягулыкны «Россия» колхозы территориясендә дә эшкә җигәргә мөмкин булачак. Сүз уңаеннан, әлеге колхоз җитәкчелеге, аның рәисе Ю. В. Терентьев авылга газ кертүгә бик җитди карады. Төрле яклардан торбалар табып, 220 йортны газ челтәре белән бәйләде. Әмма һәр хуҗалыкта да эшләр бертигез дәрәҗәдә бармый әле. Яз көне автомат газ бүлү станциясе гамәлгә кертелсә дә, әлегәчә аннан берниндн файда күрелми. Сәбәбе нәрсәдәме? Чөнки аңа тоташтырылачак Ульянов исемендәге, «Чишмә», Синдряков исемендәге, «Ленинский путь» һәм башка хуҗалыкларда газ торбалары сузу тиешенчә оештырлмаган. Җитәкчеләр моны материаллар таба алмау белән аңлаталар. Сүз дә юк, хәзерге кытлык чорында бу җиңел нәрсә түгел, халыкка газ кертү хакы да үз чиратында кыйммәтләнәчәк. Әмма ул үзен аклаячак, көнкүрешебезне бермә-бер җиңеләйтәчәк. Шуңа да хуҗалык җитәкчеләренә газ сузу эшен тиешенчә оештыру белән җиң сызганып шөгыльләнергә кирәк, чөнки хәзер районда махсус газ үткәргечләрне монтажлау оешмасы да эшли. Ә планнар зурдан— быел авыл җирендә 28 километрда газүткәргеч сузу каралган, «Россия» белән бергә Ульянов исемендәге, «Чишмә» колхозларында да табигый газдан файдалана башлау планлаштырылган. Бу җәһәттән соңгыларына бик тырышырга туры киләчәк әле, әлбәттә.

Газ—уңайлы, шул ук вакытта зур саклык, төгәллек сорый торган нәрсә. Кагыйдәләрдән аз гына тайпылу да зур бәхетсезлеккә китерүе ихтимал. Бу да шәһәр газ службасы кайгыртуында кала: рекламалар, аңлатмалар, газ приборларының төзеклеген тикшерүләр әледән-әле үткәрелеп тора.

—Коллектив үз алдындагы бурычны үтәүдә көчен кызганмый,—ди шәһәр газ службасы начальнигы Григорий Николаевич Бикиниев. Без аларга уңышлар телик. Чөнки газ һәммәбезгә кирәк.

**С. ХӘЙРУЛЛИНА.**



**«Заветы Ильича» колхозының машина-тракторлар паркында трактор бригадасы бригадиры Иван Харисанович Ворковны районда да яхшы беләләр. Тыңлаучан, сабыр, эш сөючән кеше ул.**

**Иван Харисановичның дистә елдан артык хезмәт стажы бар. Бу дәвер эчендә аңа кыр корабын да, корыч айгырны да иярләргә туры килде. Кайда да сынатмады, көнлек норманы арттырып үтәп барды ул.**

**Ворковларның гаиләсе дә үрнәк. Тормыш иптәше Анастасия Ивановна колхозда кадрлар буенча кассир-инспектор булып эшли. Уллары Евгений Совет Армиясе сафларында хезмәт итә, кызлары 8 нче классны тәмамлады.**

● **Мәктәпләрдә уку елы тәмамланды**

# ХУШ, МӘКТӘБЕМ

Бу көнне без ничә еллар буе түземсезлек белән көттек. Көтеп алган мизгел килеп җиткәч күңел иртәдән үк әллә ничек ташып-тулып торды, ямансу да, моңсу да була, җылыйсы да, көләсе дә килә. Чөнки бу классташларың белән бергә соңгы тапкыр булу, саубуллашу кичәсе бит. Шуңа да бүген әти-әниләрне, укытучыларны, мәктәп хезмәткәрләрен һәм хуҗалык җитәкчеләрен кунакка чакырдык. Һәркайсыбыз сизеп тора, безнең юллар бүгеннән соң төрле якка сузылачак. Шуңа да бик ямансу булды күңелләр. Аерылышу ямансу дип тикмәгә генә җырламый икән халкым.

Аерылышу кичәсенә килгән классташлар бүген аеруча чибәр, тыйнак, олыгайган булып күренделәр.

Кичәнең тантаналы өлешен мәктәп директоры З. З. Яруллин ачып җибәрде. Ул көчле алкышлар астында безгә урта мәктәпне уңышлы тәмамлау турында аттестатлар тапшырды. Классыбызның һәм мәктәпнең горурлыгы булган уку алдынгылары Марат Мусин һәм Гөлүсә Мөхәммәтова көмеш медальгә лаек булдылар.

Уку-укыту эшләре мөдире Р. Х. Мусина һәм класстан тыш эшләрне оештыручы Г. Г. Мөхәммәтова, класс җитәкчебез, безгә икенче анабыз кебек тәрбия, үгет-нәсихәт биреп торган кадерле кешебез Н. Х. Төхвәтуллина, әти-әниләр, мөгезле эре терлек симертү буенча хуҗалыкара берләшмә директоры Й. Г. Әхмәтсафин үзләренең чыгышларында безне олы юлга аяк басуыбыз белән кайнар котладылар, киләчәк тормышыбызда зур уңышлар, барлык хыял-максатларыбызның тормышка ашуын, кайда гына булсак та, кем булып җитешсәк тә кеше булып калуыбызны теләделәр. Без дә әти-әниләребез, мәктәп, авыл халкы йөзенә кызыллык китермәү, аларның өмет-ышанычларын акларга тырышачагыбызны белдердек, үзебез уйлап чыгарган шигъри юлларны укыдык, җырлар бүләк иттек.

Тантананың икенче өлеше уен-көлке, җыр-биюләргә, матур сүзләргә бәйләнеп мул әзерләнгән табын артында дәвам итте. Әниләребез әзерләгән ләззәтле ризыклар: пилмән, бәлеш, тутырган тавык, бавырсак, чәк-чәк, пирог, салатлар һәркем күңеленә хуш килде.

Безнең өчен соңгы мәртәбә тәнәфесне белдереп бирелгән кыңгырау аеруча күңелләрне моңсуландырды. Соңгы мәртәбә игълан ителгән тәнәфестә һәр укучы әти-әнисе, укытучылары белән биеде, матур җырлар яңгырады.

Ә соңыннан класс җитәкчебез белән бергә тегермән тугаендагы тирән сулы күл янында учак ягып, төрле уеннар уйнап, бер-беребезне онытмаска вәгъдә бирешеп һәм тагын 5 елдан нәкъ шушында очрашырга сүз куешып таңны каршыладык.

Хуш мәктәбем!
Туган йорттай кадерле син
Изге безнең күңелгә,
Балачакның якты хатирәсе,
Ядкарь булып калыр
гомергә.

**Ф. МӨХӘММӘТОВА.**



**Колхозларда бер көнен дә ял итмичә, бөтен күңеле белән колхоз эшенә бирелүчеләр байтак җыела. Елизавета Степановна Захарова шундыйларның берсе. Кышын терлекчелектә, җәен чөгендердә эшли ул. Иң мөһиме шул: кая гына эшләсә дә һәр эшен җиренә җиткереп, намус белән башкара. Озак еллар буе тырышлыгы, фидакарь хезмәте өчен Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, Мактау грамоталары белән бүләкләнде. Хәзерге вакытта Елизавета Степановна чөгендер кырында эшли.**

**Рәсемдә: Мичурин исемендәге колхоз чөгендерчесе Е. С. Захарова.**



**Бу рәсемдә сез Касыйм Гата улы Кәримовны күрәсез. Ул Ульянов исемендәге колхозның товарлыклы-сөтчелек фермасында терлекче булып 25 ел буена эшли инде. Кышын ул үзенә билгеләнгән группа малларына азык ташый, җәен көтү көтә.**

**Сыерның сөте—телендә, ди халык. Гата ага бу хакыйкатьне бик яхшы аңлый, шуңа күрә эшен бик җаваплы саный. Ул караган группа маллары сөтне яхшы бирәләр.**

## УКЫДЫГЫЗМЫ, ИШЕТТЕГЕЗМЕ?

**Финляндиянең Тышкы эшләр министрлыгы, Ленинградта консуллыкта эшләүче хезмәткәрләренең эшләү, яшәү һәм көнкүреш шартларын өйрәнгәннән соң, «хәтәр шартларда яшәгән өчен» дип, аларның хезмәт хакларын арттырган. «Хәтәр шартлар»га Ленинград азык-төлеге һәм су керә.**

x x x

**Рәсәйдә бүген миллион ярым эшсез бар. Ел азагына, диләр белгечләр, 5,6 миллионга җитәчәк.**

## ТУГАН ТЕЛДӘ УКУ

**Бу елдан башлап, С.М. Киров исемендәге Казан химия-технология институтында татарча укытылачак: көнчыгыш илләре белән уртак предприятиеләр өчен белгечләр әзерләү төркемнәре оештырылачак.**

Бу төркемдә укулар өч телдә: татар, урыс, һәм инглиз телендә барачак. Белгечлек буенча эшләп кайту һәм белемнәрне күтәрү өчен чит ил фирмаларына җибәрү дә күздә тотыла.

## МӘДӘНИЯТ ҺӘМ ИКЪТИСАД

**Кама регионында мәдәният һәм рухи тормыш үзгәреш торгызу максатында республикабызның мәдәният фонды Чистай шәһәрендә үзенең бүлеген ачарга карар бирде.**

Бу—дәүләт, аренда, кооператив, дини һәм башка оешмаларны, шулай ук аның программасын тормышка ашырырга теләге булган гражданнарны үз эченә алган мөстәкыйль, үзфинанслаучы иҗтимагый берләшмә.

Әлеге бүлек матбугат, мәгърифәт һәм кино өлкәсендә эшчәнлекне киңәйтәчәк, төрле предприятие, остаханә, салоннар ачу, лотерея уеннары, аукцион һәм сәяхәтләр оештыру белән шөгыльләнәчәк.

